# Ана –бөек исем нәрсә җитә Ана булуга

Котлау тантанасы

Тазиева.Р.С.

2010 нчы ел.

-Хермәтлеләребез сезне бүгенге бәйрәм “Аналар көне белән”

Чын күңелебездән тәбрик итәбез.”Котлау тантанабызны”ачып җибәрәбез.

1 нче алып баручы:Ана-беек исем.Ана-изгелек деньясының башлангычы.Газиз Ана булу-үзе бер бәхет,зур шатлык.Әни безне тудырган,күкрәк сетен имезгән,җыр көйләп бишектә тибрәткән,беренче елмаюыбызны күреп куанган,туган телне сеңдергән.Җиргә килгән һәр адәм баласы үзенең яшәеше белән Әнисенә бурычлы.

2 нче алып баручы:Яшь кенемдә,тен буенча ак бишекне тирбәтеп,

Еласам,күз яшьләрем серткән саен,үпкән Әни.

1 нче алып баручы:Мин сине онытмаска,геһед бирдем хәзер-күңелемә алтын кеби сүзләр тезеп киткән Әни.

2 нче алып баручы:һәр намаз саен Ходайга ялварамын мин хәзер,

“Кыл дога,бәбкәм,”-диеп,вәгъдә алып киткән Әни!

1 нче алып баручы:Миңа күкрәк сете белән кушып шәфкать канын.

Күп өчен кан-яшь түгәрлек аң биреп киткән Әни.

Халкыбыз элек-электән Ананы зурлаган.Татар халык авыз иҗатында Әниләрнең олы җаны чагыла.Үзенең акыл хәзинәсе булган мәкальләрендә халкыбыз болай дигән:

-Ана йөрәге бала өчен дәрья.

-Ана өчен баладан газиз нәрсә бар.

-Баланың телен,Анасы белер.

-Яктылык кояш янында,

Яхшылык-Ана янында.

-Ана суккан авыртмый

-Дөньяда иң йомшак нәрсә-

Ана кулы.

-Ханнан бала олы,

Баладан Ана олы.

Ана йөрәге-диңгездән тирән.

Ана куены-туннан җылырак.

Учыңда тәбә кыздырсаң да,Әниеңә булган бурычны түләп бетерә алмассың.

Ана-шәфкать диңгезе.

Һәр мәкаль нигезендә никадәр мәгънә,тәрбияви фикер ята.

2 нче алып баручы:Күренекле тәрбияче-мәгрифәтчебез Риза Фәх-Ретдин үзенең "Ислам әхлагы һәм гадәтләре"дигән хезмәтендә: "Ата-Ана сүзен тыңламау,аларга кул селтәү,шәфкатьсезлек күрсә-тү гөнаһ санала.Тормыштагы барлык хаталарны,мегаен,аңлап та, кичереп тә буладыр,әмма Ата-Анага карата мондый мөнәсәбәтне-юк!" диеп язган.

Ана йөрәгенең диңгездән тирән икәнлегенә без тагын бер кат хал-кыбыз риваятләрен тыңлап инаныйрбыз.

"Бик борынгы заманнарда яшәгән икән ди ялгыз Анасы белән бер

егет.Яшьлек-юләрлек дигәндәй,егетебез бер кызны яратып йөри икән.Егет мәхәббәтен белдереп,кызга тәкъдим ясагач,кыз:"Әгәр" Әниеңнең йөрәген алып килсән,ризалыгымны бирермен"-дип шарт куя.Нишләсен егет,кайтып,Анасының йөрәген ала һәм йөгерә-йөгерә кыз янына барырга чыга.Ул шулкадәр нык йегерә,хәтта юлда ят кан ташка да игътибар итми,абынып егыла.Шул чак егетнең кулын дагы Ана йөрәге телгә килеп:"Аягың авыртмадымы,улым?"-дигәч, егет айнып китә.....

1 нче алып баручы: Әнисө,тавыш ишетеп,бүлмәсенә йегереп керс улын Әҗәл алып китеп бара икән.Мескен Ана бер кат күлмәкчән ге нә ейдән зәмһәрир суыкка йөгереп чыккан.Каршысына ап-ак чәчле ямьсез йөзле,кара киемле карчык очраган.

-Синең йортыңа Әҗәл килде.Мин аның улыңны кая алып киткәнен беләм.Әгәр миңа яшьлегеңне,озын толымнарыңны бирсәң,үзең ми нем картлыгымны,ямьсезлегемне,чал чәчләремне алсаң,мин алар ның кая киткәннәрен сиңа әйтермен,-дигән карчык.

-Улым янымда булмагач,нигә миңа яшьлегем,нигә чибәрлегем,-ди гән Ана.-Син сораган әйберләрнең барысын да сиңа бирәм.

-Әҗәл әнә теге урманга кереп китте,-дигән яшь хатынга әйләнгән карчык.Ана йөгереп,урманга кереп киткән.Каршысына чәнечкеле к гән куагы очраган.

-Әгәр күгән үзеңнең куеныңа алып җылытсаң,мин Әҗәлнең кай тар фка киткәнен әйтермен,-дигән ул.

Ана күгән куагын нык итеп күкрәгенә кысып җылыткан.Күгәннең оч-
лы энәләре Ананың тәненә батып кергән,алардан кан тамчылаган
Күгән куагы җылынган һәм,урманда суык булуга карамастан,чәчәк-
ләргә күмелгән.

-Әҗәл күлгә таба йөгерде,-дигән күгән куагы.

Күл Анага:

-Мин энҗеләр җыям.Ә синең күзләзрең шундый саф һәм якты.Бө-
тен күз яшьләрең беткәнче еласаң,мин сине Әҗәл яши торган ярга
чыгарырмын.

-Улымны,бәгырь җимешемне кайтарыр ечен мин теләсә нәрсә дә
бирергә әзермен,-дигән Ана үксеп.Күз яшьләре беткәнче елаган ул
Аннары ике күзе дә күлгә тешеп,ике матур энҗегә әйләнгән.Күл Ана-
ны күтәреп алган да ярга илтеп куйган.Анда Ананы Әҗәл көтеп тор-
ган.

-Мин карчыкка да,күгел куагына да,күлгә дә эверелдем,-дигән Әҗәл
Ләкин синең Ана мәхәббәтең көчлерәк булып чыкты.

Шулчак Әҗәл Анага улын кире биргән һәм яшьлеген,чибәрлеген,
саф һәм якты күзләрен,озын толымнарын кире кайтарган.

-Ананың беекле генә,Ана йөрәгенең генә шул дәрәҗәдә мәрхәмәт
сыйдыра алуына-Ана турындагы риваятьләрнең кайсын алсак та
инанабыз.

2 нче алып баручы:Матур әдәбиятта Ана турында йөрәк түрендә,
җанда бөреләнгән гүзәл җырлар,саф хисле шигырьләр,күләмле

әсәрләр бик күп иҗат ителгән.Ананың йөрәк түреннән балам дип агылып чыккан хисләре турында

# Васила Хайруллинаның “Балам өчен” шигырен тыңлап узыйк.

Бар хисләрем,бар хәсрәтем балам ечен,
Хөрмәтем дә,хезмәтем дә балам өчен.
Үкенүләр,үтенүләр балам өчен.
Йокысыз төн,тынгысыз кен балам өчен.
Утка суга төшүләрем балам өчөн.
Барыр юлдан туктауларым балам өчен
Таңнан әзөр кайнар ашым балам өчен.
Тәгәрәгән кайнар яшьтә балам ечен
Иртә-кичен йерәк хисем балам өчен.
Барлык эшем,барлык көчем балам өчен
Янам,түзәм,күнәм,көям балам өчен.
Горур башым иям балам өчен
Төннәр туа,таңны кетәм балам ечен.
Күкрәгемдә җырлар йөртәм балам ечен
Күкрәгемдә сөю уты яна балам өчен.
Бер шатлыгы мең хәсрәтне юып ала.
Озын кунак булып кунмый кара болыт.

Ярый әле яралганмын Ана булып.

1 нче алып баручы: Ә икенче шагыйребез үзенең шигырендә безне татар-мөселман хатыннарының гүзәллеген,җир Анабыз-табигать гүзәллеге белән тиңләп менә ничек яза.

# Г.Латыйпова.”Татар хатынына”.

Каеннарның зифалыгы синдә,
Моңсулыгы алтын көзләрнең.
Аяз кеннең күген хәтерләтеп,
Нур сибәләр синең күзләрең
Инешләрнең сабырлыгы синдә,
Чишмә суларының сафлыгы,
Моң-сагышлар сарган күңелеңдә
Яңа яуган карлар аклыгы,
Сәдалектә,сәгадәт тә синдә,
Эчкерсезлек бизи үзеңне.
Якты нурын сипкән ай-кояштай
Күрәм синең күркәм йөзеңне.
Тик сиңа хас асыл сыйфатларны
Мөмкинме соң санау барсын да
Тының ереп,мәрхәмәтле җанны
Төзәтерлек тылсым бар синдә.

Әйе,безнең мөселман хатыны гына шулай гүзәл була ала.Ана-

Йерәге,күңеле,мәрхәмәте генә,чиксез диңгез,дәрьядай.Безгә бик авыр минутларыбызда,чарасызлыктан бегелеп төшеп “булмый,юк дигән вакытларыбызда,кире башыбызны югары күтәреп,тагын алга барырга”тылсымлы җанны дәваларлык тыны белән” кеч бирә ала.Ана гына үз баласы ечен тенендә,кенендә “Балам өчен” дип яна-кея.

Ана! –Әннә -Әни!-нинди матур бөек күңелләрне дә җылыта-яктырт алырлык тирән мәгънәле,затлы сүзләр!юкка гына Ана сүзе Ватан сүзе белән янәшә йөрми бит.Күңелебездә булган бетен рәхмәтебезне дә шушы гади сүзгә салабыз.Ана-бу деньяга яңа кеше булә итә,аны тәрбия кыла.Ул булганда тормышыбыз матур,өебез нурлы,күңелебез күтәренке.

Ана-нинди бөек исем
Нәрсә җитә Ана булуга.
Хатын-кызның бөтен матурлыгы
Бетен күрке Ана булуда.

Әйе,Ана булу олы бәхет,бу бәхетне һәр хатын-кызга да татырга язсын һәм чын Ана булып,ул яңа кеше булып үсәргә тәрбия бирергә үз газиз,деньяга китергән Анага гына насыйп итсен. Юкка гына “Бала-йөрәк ите”дигән яки “Кем тудырган”шуңа тәрбияләргә насыйп булсын дигән тешенчәләр барлыкка килмәгәндер.Үз Анаң гына сиңа йөрәген ярып бирә ала.

1 нче алып баручы: Рәхмәт сезгә Аналар,

Рәхмәт сезгә шуның өчен!

Бу якты сихри дөньяга

Безне тудырган өчен

Хисләребезне түгик тагын

Сездән башка кайсына?

Рәхмәт Сезгә Аналар

Рәхмәт Сезгә барсына!

Кадерле Әниләребез тагын бер кат Аналар көне белән тәбрик итәбез.Гаиләләрегездә чыннан да кадерлеләр булып калыгыз. Гаиләләребездә аерым борчулар,кайгылар үтеп кермәсен.Тигез канатлы булыгыз."Әнием"дип торучы балаларыбыз сау-сәламәт булсыннар.Бәхетле булыгыз! Ана-исемен горур йөртергә насыйп булсын.